Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

«12» сентябрь 2019 ел №80

Җир кишәрлегеннән һәм капиталь
төзелеш объектыннан файдалануның
шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт
бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 366 номерлы карары белән расланган «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2015 елның 30 сентябрендәге 709 номерлы боерыгы, Әлмәт шәһәре башлыгының 2019 елның 22 июлендәге 22 номерлы «Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында»гы карары нигезендә 2019 елның 20 августындагы 6446и номерлы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре бәяләмәсе нигезендә (“Альметьевский вестник” газетасы 2019 елның 5 сентбярендәге 36 номерлы басмасы),

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалану төренә - «гомуми мәйданы 150 кв.метрдан артмаган беренче кирәкле товар кибетләре», җир кишәрлекләреннән файдалану рөхсәт ителгән төрләре классификаторы буенча 4.4 нче код «кибетләр» - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Утыз Имәни урамы, көньяк-көнчыгыштан з/у 2а адресы буенча урнашкан 192 кв. м мәйданлы формалаша торган җир кишәрлегенә карата.

2. «Әлмәт муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына (Пузырева И.Г.) җибәрергә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев